| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**<br>**ГЛАВА БУРМЕТЬЕВСКОГО**<br>**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**<br>**НУРЛАТСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**<br>**КИЕКЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ**<br>**РАЙОНЫ**<br>**БАШЛЫГЫ** |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Киекле ав. **КАРАР**

«29» марта 2024 г. № 1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге Үрнәк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Нурлат муниципаль районының Киекле авыл җирлеге Уставының 23 статьясы нигезендә, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы

**КАРАР ИТТЕ**:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылында яшәүче гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 10 апреленә Үрнәк авылында яшәүче гражданнар өчен 08 сәгать 00 минутка билгеләргә: Үрнәк авылы, Нагорная урамы, 52а йорт адресы буенча элек расланганнарга өстәмәләр кертү мәсьәләсе буенча:

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 08.11.2023 ел, № 3 карары;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылы торак пунктында гражданнар Җыенының 08.11.2023 ел, № 4 карары.

2. Үрнәк авылында яшәүче гражданнар өчен гражданнар җыенын үткәрү һәм оештыру Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан тәэмин ителә.

3. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

«Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 08.11.2023 ел, № 3 һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Киекле авыл җирлегенең Үрнәк авылы торак пунктында гражданнар

жыены 08.11.2023 ел, № 4 карарга түбәндәге үзгәрешләрне кертүгә килешәсезме:

Киекле авыл җирлегендә яшәүче һәм теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидлардан, балачак инвалидлары, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, СВОда катнашучылардан тыш 2024 елда үзара салым тәртибендә 1000 сум күләмендә алынган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алдан расланган эшләр исемлеген үзгәртергә:

- урам яктырту җайланмасы (товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу);

торак пункт территориясен төзекләндерү (халыкның күпләп ял итү урыннары (парклар, спорт мәйданчыклары, балалар мәйданчыклары һәм халыкның башка күпләп ял итү урыннары) һәм аларга якын территорияне төзекләндерү).

« РИЗА» «КАРШЫ».

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (игълан итәргә), Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Үрнәк авылының мәгълүмат стендларында халык җыенын үткәрү датасына кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Киекле авыл җирлеге башлыгы Л.И. Кашапова